Республика Татарстан
МУНИЦИПАЛЬНОЕ
ОБРАЗОВАНИЕ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
**С О В Е Т**
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»

Татарстан Республикасы
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
**С О В Е Т Ы**

---

## РЕШЕНИЕ КАРАР

**2023 елның 18 декабреннән** **№ 43**

«Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 03 октябрендәге 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Зеленая Роща авыл җирлеге" муниөипаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. « Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 03 октябрендәге 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6 пунктының икенче абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4.10 пункт гамәлдән чыккан дип танырга;

4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.13. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 4.7 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, сыйныф чинын барлык кирәкле документлар белән җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш урамы, 1 йорт (Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы), Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32 йорт (СДК бинасы), адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

« Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.А.Потапов.